СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

30.09.2019 года — с. Верхний Услон — № 49-569

**« Югары Ослан муниципаль районында 2018-2022 елларга яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру барышы турында**

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы А. Н. Федотовның «2018-2022 елларга Югары Ослан муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру нәтиҗәләре турында мәгълүматын тыңлап тикшергәннән соң,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**КАРАР ИТТЕ:**

1. Югары Ослан муниципаль районында «2018-2022 елларга яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты:

- авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру буенча эшне дәвам итәргә.
- яшьләрнең лидерлык сыйфатларын ачыклау максатыннан интеллектуаль-иҗади һәм физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрү буенча эшне көчәйтергә;
- Югары Ослан муниципаль районы территориясендә яшьләрнең хокуклары һәм мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итәргә;
- җирле дәрәҗәдә социаль, икътисади һәм иҗтимагый бурычларны хәл итүгә яшьләрне җәлеп итү буенча чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру;
- яшьләрнең хезмәт белән тәэмин ителешенә ярдәм итү;
-яшьләр оешмаларының муниципальара хезмәттәшлеген тормышка ашыру.

3. Җирлек башлыкларына авылда яшьләрне эш белән тәэмин итү һәм районның социаль-икътисади үсеш программаларын тормышка ашыруга

җәлеп итү буенча даими эш алып барырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Югары Ослан муниципаль районы Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет рәисе**,
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Башлыгы** **М.Г. Зиатдинов**